**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт, штп. Кама Тамагы,
422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 8 октябрендәге №548

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 30 сентябрендәге899 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында " 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 7 пунктының «в» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 900 номерлы карары белән расланган милеккә муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.8.2 пунктының 2.8.1 пунктчасында:**
**3 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа мондый гариза

белән әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәттә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан мөрәҗәгать иткән очраклар керми, федераль законнар нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга хокукы булган, Россия Федерациясе субъектлары законнары белән йә Россия Федерациясе Җир кодексының 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр андый җир кишәрлеге бакчачылык булса), шулай ук гражданнар бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә үз ихтыяҗлары өчен урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);

16 өлештә «**чикле**» сүзен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов